СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2021 г. Заинск № 187

**«Зәй муниципаль районында территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 04 маендагы 289 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәреш кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге N45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районында территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 04 маендагы 289 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган Зәй муниципаль районында территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 5.2 пунктның 2 пунктчасында «язмача рәвештә» сүзләреннән соң «яисә электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN. RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**